СОВЕТ БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
30 «июнь» 2021 г.

**КАРАР**
№27

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Борнак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм 2020 елның 31 июлендәге Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 259-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «санлы финанс активлары, санлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында»2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 26.12.2020 N 97-ТРЗ номерлы ТР Законы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Борнак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге Советының 2016 елның 13 апрелендәге 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында пайларның катнашу өлеше), санлы финанс активлары, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы соңгы өч елда хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Борнак авыл җирлеге башлыгы Ш.М.Хабибуллин